**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарлы Матак,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Базарлы Матак авылы** **КАРАР**

2022 елның 25 мае 181№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 10 июнендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында» 219 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законны, 2021 елның 11 июнендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»170-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге нигезләмә Әлки муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының (алга таба - актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне , эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган актлар проектында гамәлдәге норматив хокукый актларны ачыклау максатларында муниципаль норматив хокукый актларга яисә аларны кертүгә ярдәм итүче, эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының, Әлки муниципаль районы

бюджетының нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләр, эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләр, шулай ук конкуренцияне чикләүгә нигезсез ярдәм итә торган нигезләмәләргщ экспертиза (алга таба норматив хокукый актлар) уздыру тәртибен билгели.

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны территориаль үсеш буенча җитәкче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче: И.В. Юсупов